| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.08.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1677** |

2018-2019 уку елында Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы нигезләмәне раслау турында» 1441 номерлы карарын, Россия Федерациясе оборона министрының һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Россия Федерациясе гражданнарын оборона өлкәсендә башлангыч белемнәргә өйрәтүне оештыру һәм урта (тулы) гомуми белем бирү мәгариф учреждениеләрендә, башлангыч һөнәри һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрендә һәм уку пунктларында хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләүне оештыру турында инструкцияне раслау турында» 2010 елның 24 февралендәге 96/134 номерлы уртак боерыгын үтәү йөзеннән һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. 2018-2019 уку елында Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар планын расларга (кушымта).
2. Җитәкче урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В.Афанасьевга:

- урта (тулы) гомуми белем бирү учреждениеләрендә «Хәрби хезмәт нигезләре» программасы буенча укыту методикасын камилләштерергә;
- запастагы офицерлар яисә кабат әзерлек үткән офицерлар арасыннан хәрби хезмәт нигезләре укытучылары, шулай ук бу өлкәдә кирәкле белемгә ия педагогик югары уку йортларын тәмамлаучылар тарафыннан белем бирү учреждениеләрен туплау өчен кирәкле чаралар күрергә;
- белем бирү учреждениеләренең уку-матди базасын РФ Оборона министрлыгының 96 нчы номерлы һәм РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2010 елның 21 февралендәге 134нче номерлы уртак боерыклары һәм федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры китерү;

- мәгариф учреждениеләренең спорт шәһәрчекләрен кирәкле элементлар, шул исәптән каршылыклар полосасы элементлары белән җиһазландырырга;

- хәрби хезмәт нигезләре буенча дәресләр үткәрү өчен белем бирү учреждениеләренең спорт залларын, спорт шәһәрчекләрен, тирларын актив кулланырга;

- «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы буенча мәгариф учреждениеләре кабинетларын яңа методик әсбаплар, плакатлар, хәрби һәм хәрби-патриотик юнәлештәге стендлар белән бизәү буенча акча бүлеп бирүгә гаризалар әзерләргә ;

- гомуми белем бирү мәктәпләренең 10 сыйныф укучылары һәм урта махсус белем бирү уку йортларының соңгы курс алды укучылары белән укуның соңгы этабында Казан шәһәренең «Казан югары танк команда Кызыл байрак училищесы» базасында хәрби коралдан атуны оештыру белән биш көнлек күчмә уку-укыту җыеннары үткәрергә;

- гражданнарны хәрби исәпкә кую буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариатына ярдәм итәргә;

- Россия Федерациясе Оборона министрлыгы хәрби-белем бирү учреждениеләренә укырга керү буенча яшүсмерләргә юнәлеш бирү буенча актив эш алып барырга;

- хәрби-патриотик, спорт клубларын, түгәрәкләрне һәм секцияләрне һәрьяклап үстерергә һәм аларга ярдәм итәргә;

- Ватанны саклаучылар көнен бәйрәм итү чорында шәһәр һәм авыл мәктәпләре укучылары белән саф смотрларын оештырырга һәм гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә хәрби-патриотик юнәлештәге чараларда катнашу өчен бердәм хәрби кием формасы алырга тәкъдим итәргә.

3. Зеленодольск муниципаль районының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе башлыгы Р.Р. Бареевка Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы белән берлектә яшьләрне патриотик тәрбияләү, хәрби хезмәт һәм хәрби-һөнәри юнәлеш алуга кызыксынуны арттыру буенча үткәрелә торган мәдәни һәм спорт чараларының массакүләмлеген тәэмин итәргә;

- хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар арасында спортның хәрби-гамәли төрләре буенча спорт ярышларын планлаштырырга һәм уздырырга;

- көзге һәм язгы чакырылыш чорында «Хәрби хезмәткә алынучылар көне» үткәрергә;

- хәрби-патриотик юнәлештәге яшьләр клублары һәм оешмалары эшен оештыру һәм камилләштерү, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы хәрби комиссариатына бирергә;

- РФ Кораллы Көчләре сафларына хәрби хезмәт үтү өчен җибәрелгән Зеленодольск муниципаль районы яшьләре арасыннан чакырылучыларны тантаналы озатуны оештырырга.

4. «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы Т.В. Сабурскаяга (килешү буенча) хәрби исәпкә алынганнан соң һәм хәрби хезмәткә чакырылу нәтиҗәләре буенча профилактик медицина тикшерүләре нәтиҗәләре буенча хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге һәм хәрби хезмәткә чакырылу яшендәге мохтаҗ гражданнарга дәвалау-сәламәтләндерү чараларын вакытында һәм тулы күләмдә үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен конторльдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.В. А.В.Старостинга йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

ЗМР БК карарына кушымта
___________2018 № _______

2018-2019 уку елында Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар

**ПЛАНЫ**

| **№** *т/б* | Чараның атамасы | Җаваплы башкаручы | Үткәрү срогы |
|---|---|---|---|
| | **I. Оештыру чаралары** | | |
| 1. | Төп планлаштыру документларын эшләү:<br>а) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесенең 2018-2019 уку елында Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында карар проектын;<br>б) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесенең 2018-2019 уку елында хәрби хезмәт нигезләре буенча укытучыларның уку-укыту җыеннарын оештыру һәм үткәрү турында боерык проектын. | Зеленодольск шәһәре һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты<br><br>Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | Уку елы дәвамында |
| | **II. Хәрби хезмәткә әзерләүне кадрлар белән һәм уку-укыту-методик яктан тәэмин итү** | | |
| 1. | Белем бирү оешмаларын тормыш иминлеге нигезләре укытучылары – оештыручылары белән комплектлау | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре | Даими |
| 2. | «Тормыш иминлеге нигезләре» курсын укыту өчен уку-методик һәм күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин итүдә белем бирү учреждениеләренә ярдәм күрсәтү | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | Даими |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Тормыш иминлеге нигезләрен оештыручы укытучылар белән укытуны һәм уку-методик җыеннар үткәрүне оештыру | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | Уку елы дәвамында |
| **III. Гражданнарны хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләү** | | | |
| 1. | Оборона өлкәсендә гражданнарны башлангыч белемнәргә өйрәтүне оештыру һәм гражданнар оборонасы буенча алар тарафыннан күнекмәләр алу | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре | Уку елы дәвамында |
| 2. | Белем бирү оешмаларының 10 сыйныф укучылары һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларының чыгарылыш алды курслары укучылары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча уку-укыту җыеннары үткәрү | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты | 2019 елның мае |
| 3. | Мәгариф учреждениеләрендә хәрби хезмәт нигезләре буенча слетлар, ярышлар, конкурслар үткәрү | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре | Уку елы дәвамында |
| **IV. Гражданнарны хәрби-патриотик тәрбия бирү** | | | |
| 1. | Гражданнарны хәрби-патриотик тәрбия бирү мәсьәләләре буенча конференцияләр һәм семинарлар үткәрү | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Зеленодольск муниципаль районының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | Уку елы дәвамында |
| 2. | Мәгариф учреждениеләрендә Батырлык дәресләре, Ватан тарихына багышланган класстан тыш чаралар үткәрү | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре | Уку елы дәвамында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Ватанны саклаучылар көненә һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең еллыгына багышланган оборона-массакүләм һәм спорт чаралары үткәрү | Зеленодольск муниципаль районының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | Уку елы дәвамында |
| 4. | «Хәрби хезмәткә чакырылу көне» социаль-патриотик акция үткәрү | Зеленодольск муниципаль районының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 27.10.2018<br><br>2019 елның 27 апреленә кадәр |
| 5. | Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылырга тиешле гражданнар арасында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең еллыгына багышланган спорт-гамәли һәм спорт-техник төрләре буенча ярышлар үткәрү | Зеленодольск муниципаль районының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | Уку елы дәвамында |
| 6. | Яшьләр тарафыннан Татарстан Республикасының Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты вәкилләре, шулай ук Бөек Ватан сугышы, Әфганстандагы сугыш, Төньяк Кавказдагы контртеррористик операция ветераннары һәм башкалар белән очрашулар уздыру. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты | Уку елы дәвамында |
| **V. Медицина таныклавы һәм медицина тикшерүе** | | | |
| 1. | Гражданнарны медицина таныклавында катнашучы табиб-белгечләре белән инструкторлык-методик җыелыш үткәрү | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты | 20.09.2018 гә кадәр 15.03.2019 |
| 2. | Гражданнарны башлангыч хәрби исәпкә куйганда медицина таныклавын һәм тикшерүен оештыру һәм үткәрү | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск | 01.04.2019 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | районы Хәрби комиссариаты | |
| 3. | Гражданнарны беренче тапкыр хәрби исәпкә кую чорыннан алып, аларны хәрби хезмәткә чакыруга кадәр, гражданнарга тулы күләмдә медицина тикшерүе уздыруның вакытында төгәлләнүен контрольдә тотып, аны уздыру | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты | 30.12.2018, 01.04.19-15.07.2019 |
| **VI. Дәвалау-савыктыру эше** | | | |
| 1. | Башлангыч хәрби исәпкә кую нәтиҗәләре буенча 1, 2, 3 нче исемлекләргә кертелгән, шулай ук хәрби хезмәткә чакыру йомгаклары буенча вакытлыча яраксыз дип танылган 2002 елда туган гражданнар белән дәвалау-савыктыру чараларын үткәрү | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты | Уку елы дәвамын да |
| 2. | 15 – 16 яшьтәге (2003-2004 елда туган) гражданнарны башлангыч хәрби исәпкә куйганга кадәр, профилактика медицина тикшерүләре үткәрү | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты» ДАССУ | 01.04-30.05.2019 |
| 3. | Югары белем бирүче мәгариф оешмаларының көндезге укыту формасындагы 1, 3, 5 (6) курс студент егетләрен профилактика медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча, хәрби хезмәткә әзерләү максатларында, дәвалау-савыктыру чараларын үткәрү | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты | 01.11-30.12.2018, 11.01-15.07.2019 |
| 4. | Гражданнарны хәрби хезмәткә чакырганга кадәр, алар белән дәвалау-савыктыру эшләре үткәрүнең нәтиҗәлелеген контрольдә тоту | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты | 30.12.2018 11.01-15.07.2019 |
| 5. | Укуның көндезге формасында югары һөнәри белем бирү учреждениеләренең 1,3,5 (6) курс студентларына профилактик медицина тикшерүе үткәрү | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты | Ел дәвамында килештерелгән график |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | буенча |
| **VII. Гражданнарны үз ихтыярлары белән хәрби хезмәткә әзерләү** | | | |
| 1. | Россия Федерациясе Оборона министрлыгының югары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләренә керү өчен гражданнарны сайлап алуны оештыру | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты | 01.09.18-20.05.2019 |
| 2. | Суворов хәрби училищесына, хәрби-музыка училищесына, Нахимов хәрби-диңгез училищесына, кадетлар корпусына, керү өчен кандидатларны туплау һәм җибәрү | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе. | 01.02-30.05.2019 |
| *3.* | Спортның хәрби-гамәли төрләре буенча клублар, секцияләр, түгәрәкләр эшен оештыру һәм аларның слетларын үткәрү | Зеленодольск муниципаль районының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | Уку елы дәвамында |
| 4. | Суворов хәрби училищесына, хәрби-музыка училищесына, кадетлар корпусына, Нахимов хәрби-диңгез училищесына керү өчен сайлап алу һәм җибәрү буенча тормышта авыр хәлдә калган ятимнәр һәм балалар белән эшләү | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | Уку елы дәвамында |
| **VIII. Гражданнарның хәрби-гамәли спорт төрләре белән шөгыльләнүләре** | | | |
| 1. | Спорт клубларын һәм секцияләрен ачуда мәгариф учреждениеләренә, районның иҗтимагый берләшмәләренә ярдәм күрсәтү | Зеленодольск муниципаль районының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | Уку елы дәвамында |
| *2.* | Районда спорт клублары һәм спортның хәрби-гамәли төрләре буенча секцияләр арасында ярышлар оештыру һәм уздыру | Зеленодольск муниципаль районының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | Уку елы дәвамында |
| **IX. Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүнең сыйфатын контрольдә тоту** | | | |
| 1. | 15-16 яшьлек яшүсмерләр белән дәвалау-савыктыру чараларын уздыруның тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тотуны тәэмин итү һәм алдан ук хәрби исәпкә куелганчы профилактик медицина тикшерүләре (диспансеризация) | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ | Даими |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | нәтиҗәләре буенча мониторинг үткәрү | | |
| 2. | Муниципаль берәмлекләрдә гражданнарның физик әзерлеген контрольдә тотуны тәэмин итү | Зеленодольск муниципаль районының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | Даими |
| 3. | Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан патриотик юнәлешле клублар исәбен алып бару | Зеленодольск муниципаль районының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | Даими |